СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 154 от 27.09.2022
на № _________от ______________

# КАРАР

Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 9 апрелендәге 208 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында Нигезләмә» 2018 елның 9 апрелендәге 208 номерлы карары белән расланган, 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Башлыгының, Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасарының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, Саба муниципаль районы Контроль-хисап палатасы Рәисенең айлык акчалата бүләкләү күләмен 1,04 тапкыр арттырырга.

**2.** Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган муниципаль хезмәтнең алар биләгән вазыйфалары нигезендә 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.

**3.** Әлеге карарның 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт Вазыйфаларының кече төркеме

белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 тапкырга индексацияләргә һәм 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

**4.** Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**4.1.** 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 11 958 сум күләмендә расларга.»;

**4.2.** 1 нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

**5.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, әлеге карар нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2022 елның 1 октябреннән гамәлдә була башлау белән, яңа штат расписаниеләрен расларга.

**6.** Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

**7.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
2022 елның 27 сентябрендәге 154
номерлы карарына
1 кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасарының, Саба муниципаль районында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Контроль-хисап палатасы Рәисенең акчалата бүләкләү күләмнәре**

| Вазифа исемнәре | Акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 31 660 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 28 494 |
| Депутатлар | 15 525 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 13 192 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисе | 28 494 |